**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Баязитов Илдар Рәфкать улына – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе, «Ярдәм» ислам хәйриячелек милли фонды советы рәисенә;

2) Ильясов Марат Мөдәррис улына – «МИН БУЛДЫРАЧАКМЫН» сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә булышлык итү автоном коммерциячел булмаган оешмасы рәисенә;

3) Юлашев Әхәт Гайнулла улына – «Россия ветераннар берлеге» гомумроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисенә;

4) «Федераль татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасына;

5) «Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасына;

6) Әлмәт муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасына;

7) «Бала – могҗиза» дәвалау педагогикасы үзәге автоном коммерциячел булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасына;

8) «НеЗаМи» балаларга һәм инвалидларга булышлык итү хәйриячелек фондына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 13 октябрь
№ ПУ-681